Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Варклед- Бодья торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**30.10.2025** **№ 1**

Гамәлдәге законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, 2025 елның 30 октябрендә 19 сәгать 00 минутта “Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Бодья торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекчеләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ирләре яки хатыннары), I төркем инвалидлардан, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге ялгыз гражданнардан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш), 2026 елда үзара салым акчасын 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне:

1) Варклед-Бодья торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (СК тыкрыгына, борылу мәйданчыгына юл салу өчен таш алу һәм җәю, автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

2) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (казу, төзелеш-монтаж эшләре һәм торак пунктын су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар);

3) Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электротоварлар сатып алу һәм урам яктырткычларын урнаштыру, электрикка хезмәт хакы түләү, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

4) Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (янгын сүндерү машинасы тоту; ягулык-майлау материаллары, запас

частьләр, янгын сүндерү җиңсәләре, кирәк-яраклар сатып алу, янгын депосына гараж ишекләре монтажлау һәм кую, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

5) Торак пунктын төзекләндерү (юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм хезмәт килешүе буенча трактористка түләү).

башкаруга юнәлтүгә, кулланууга ризамы?" дигән сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

« РИЗА» «КАРШЫ»

Беркетмә нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 247 катнашучы кертелде. Гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 146 кеше, бу 59,1% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 146 катнашучысы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды :

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед- Бодья торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Әгерҗе муниципаль районы «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед- Бодья торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр ) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары, ире яки хатыны), Ітөркем инвалидлардан, өлкән яшьтәге ялгыз гражданнардан (80 яшькә җиткәннәрдән), көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш) 2026 елда үзара салым акчаларын 1000 сум күләмендә кертергә.

3.Алынган акчаларны, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

1) Варклед-Бодья торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (СК тыкрыгына, борылу мәйданчыгына юл салу өчен таш алу һәм җәю, автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

2) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (казу, төзелеш-монтаж эшләре һәм торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар);

3) Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электротоварлар сатып алу һәм урам яктырткычларын урнаштыру, электрикка хезмәт хакы түләү, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

4) Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (янгын сүндерү машинасы тоту; ягулык-майлау материаллары, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

5) Торак пунктын төзекләндерү (юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм хезмәт килешүе буенча трактористка түләү).

6) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышы ветераннары, тыл хезмәтчәннәре, локаль сугышчыларда катнашучылар өчен һәйкәл әзерләү һәм урнаштыру);

4. Карарны Көчек авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы сайтында (https://agryz.tatarstan.ru), «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
авыл җирлеге башлыгы Ә.Р. Төхфәтуллина